ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 июль 2024 ел № 4596

Башкарма комитетның «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 маендагы 3673 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турындагы нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 маендагы 3673 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «, рөхсәтне гамәлдән чыгару» сүзләрен өстәргә;

2) 1 пунктта «конструкциясен» сүзенннән соң «, рөхсәтне гамәлдән чыгару» сүзләрен өстәргә;

3) административ регламентта:

- исемендә һәм 1 пунктта «элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару» сүзләрен «, рөхсәтне гамәлдән чыгару» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.8.2 пунктның 4 һәм 6 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәяне итәргә:

«4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең барлыкка килгән төзелешләренең тышкы архитектура күренешен бозу;»;

«6) 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5 өлешендә (реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми мөлкәте файдаланылган очракта), 5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә билгеләнгән таләпләрне бозу;»;

4) административ регламентка 4 нче, 5 нче кушымталарны әлеге карарга 1 нче, 2 нче кушымталарда каралганча бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы

рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 15 июлендәге
4596 номерлы карарына
1 нче кушымта

4 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесе
___________________________

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү турында

гариза

Гариза бирүче турында мәгълүматлар:

Ф.И.А.и., туу датасы, шәхесне раслаучы документ мәгълүматлары, почта адресы:

__________________________________________________________________________________;

(физик зат, шул исәптән шәхси эшмәкәр сыйфатында теркәлгән зат өчен)

юридик затның тулы исеме: ___________________________________________________________

__________________________________________________________________________________;

(юридик зат өчен)

салым түләүченең идентификация номеры (ИНН), юридик адресы ___________________________

__________________________________________________________________________________;

элемтә мәгълүматы: (тел.): _________________________________________________.

Гариза бирүче вәкиленең мәгълүматлары (Ф.И.А.и., гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ реквизитлары, гариза бирүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документны биргән орган) ___________________________________________________________

__________________________________________________________________________________;

(гариза бирүче исеменнән муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап вәкил мөрәҗәгать иткән очракта күрсәтелә)

элемтә мәгълүматы: (тел.): _________________________________________________.

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирүене сорыйм, аның турында мәгълүматлар әлеге гаризага теркәлә торган реклама конструкциясе проектында күрсәтелгән.

Реклама конструкциясе тоташтырылган мөлкәт турында мәгълүматлар:

реклама конструкциясе тоташтырыла торган күчемсез милек объектының исеме һәм билгеләнеше

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________;

(реклама конструкциясе тоташтырыла торган бинаның (төзелмәнең, корылманың), җир участогының исеме һәм билгеләнеше (спорт, сәүдә, күңел ачу объекты, җиңел автотранспортны саклау объекты һ. б.), реклама конструкциясе тоташтырыла торган күчемсез милек объектының кадастр номеры (объект дәүләт кадастр исәбен узган очракта) күрсәтелә)

реклама конструкциясе тоташтырылган мөлкәтнең милек формасы:

шәхси / муниципаль / федераль / Татарстан Республикасы милке / дәүләт милке чикләнмәгән (кирәклесенең астына сызарга);

реклама конструкциясе тоташтырыла торган мөлкәткә законлы хуҗа булу төре һәм нигезе: ______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________;

(мөлкәт хуҗасы, мөлкәт хуҗасының хокук төре күрсәтелә)

реклама конструкциясе тоташтырыла торган бинаның (төзелмәнең, корылманың) тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә мөнәсәбәте ______________________________________________

______________________________________________________________________________.

(бина (төзелмә, корылма) тарихи һәм мәдәни ядкәр булган очракта, объектның тарихи-мәдәни әһәмияткә ия категориясе күрсәтелә)

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәнең гамәлдә булу срогы

«___» ____________ 20___ елдан «___» ____________ 20___ елга кадәр.

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү өчен дәүләт пошлинасын түләү турында документ реквизитлары:

______________________________________________________________________________

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен минем адреска түбәндәге ысул белән бирүне (җибәрүне) сорыйм:

☐ Электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына

☐ КФҮгә

Кушымталар:

______________________________________________________________________________.

(Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар)

Гариза бирүче __________________ (____________________________________________)

(имза) (гаризаны имзалаган затның фамилиясе, инициаллары, аның вазыйфасы)

** реклама конструкциясен бинада (төзелмәдә, корылмада) урнаштырган очракта, әлеге юлда бинада урнашкан аерым бүлмәләрнең түгел, ә бөтен бинаның (төзелмәнең, корылманың) кадастр номеры күрсәтелә;*

*** реклама конструкциясен төзелеше тәмамланмаган объектта урнаштырган очракта, капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт реквизитлары, төзелеше тәмамланмаган объектка милек хокукын теркәү турында таныклык реквизитлары күрсәтелә (теркәү үткәрелгән булса). Реклама конструкциясен гомуми милек булып торучы мөлкәттә урнаштырган очракта, әлеге юлда шул хәл күрсәтелә, юлда каралган башка мәгълүматлар күрсәтелми.*

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2024 елның 15 июлендәге
4596 номерлы карарына
2 нче кушымта

5 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесе

___________________________

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә
рөхсәтне гамәлдән чыгару турында
гариза
№ ________ «__» _______________ 20__ ел

Гариза бирүче турында мәгълүматлар:
Ф.И.А.и., туу датасы, шәхесне раслаучы документ мәгълүматлары, почта адресы:
_____________________________________________________________________________;
(физик зат, шул исәптән шәхси эшмәкәр сыйфатында теркәлгән зат өчен)
юридик затның тулы исеме: ______________________________________________________
____________________________________________________________________________;
(юридик зат өчен)
салым түләүченең идентификация номеры (ИНН), юридик адресы: _______________________;
элемтә мәгълүматы: (тел.): ________________________________________________.
Гариза бирүче вәкиленең мәгълүматлары (Ф.И.А.и., гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ реквизитлары, гариза бирүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документны биргән орган)
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________;
(гариза бирүче исеменнән муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап вәкил мөрәҗәгать иткән очракта күрсәтелә)
элемтә мәгълүматы: (тел.): ________________________________________________.
«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 18 өлеше нигезендә, «____» ________ 20___ елда бирелгән № ______
_____________________________________________________________________________
реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгаруыны сорыйм.
Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен минем адреска түбәндәге ысул белән бирүне (җибәрүне) сорыйм:

☐ Электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына

☐ КФҮгә

Кушымталар:
_____________________________________________________________________________.
(Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар)
Гариза бирүче __________________ (_____________________________________________)
(имза) (гаризаны имзалаган затның фамилиясе, инициаллары, аның вазыйфасы)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева